





# «Рус телле балаларның УМК буенча программа материалын үзләштерүләрен тикшерү өчен мультимедиа дидактик уеннары (4-7 яшь)» эшкәртмәсенә методик ярдәмлек



**Яр Чаллы Татарстан Республикасы**
**2013**

**Төзүчеләр:**

Сунгатуллина Р. Ф. - балаларга татар теле өйрәтү буенча югары категорияле тәрбияче,
Шәйхетдинова Р. С - балаларга татар теле өйрәтү буенча беренче категорияле тәрбияче,
Хурмаева Г. М.- балаларга татар теле өйрәтү буенча югары категорияле тәрбияче.
Яр Чаллы шәһәренең “Көлсылу” 44 нче катнаш балалар бакчасы” муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе”

Бу методик ярдәмлек балалар бакчасында эшләүче, балаларга татар теле өйрәтү буенча тәрбиячеләр өчен каралган. CD дискасына 4 яшьтән 7 яшькә кадәрле балаларның программа материалын үзләштерүен тикшерү өчен мультимедиа дидактик уеннар һәм уен ситуаицяләре яздырылган. Бу методик ярдәмлек аның кушымтасы булып тора.

Мультимедиа дидактик уеннары кулլануның иң мөһим бурычы: балаларны татар теленә өйрәткәндә укыту методик комплекты буенча өйрәнгән программа материалын үзләштерүләрен билгеләү .

Методик ярдәмлеккә тупланган материаллар балалар бакчасы педагогларына зур ярдәмлек булыр дип уйлыйбыз.

## Эчтәлек


| | |
|---|---|
| Кереш сүз...................................................................... | 4 |
| Яшь үзенчәлекләре буенча уеннар бүленеше...................................................................... | 6 |
| Уртанчылар төркеме өчен дидактик уеннар...................................................................... | 7 |
| Зурлар төркеме өчен дидактик | 10 |

| | |
|---|---|
| уеннар.................................. | |
| Мәктәпкә әзерлек төркеме өчен дидактик уеннар......................................................................... | 13 |
| Күзгә гимнастика...................................................................... | 17 |
| Кулланылган әдәбият......................................................................... | 18 |


## Кереш сүз

**Максат:** Мәктәпкәчә яшьтәге татар теле өйрәнүче балаларның (4-7 яшь) укыту методик кулланма буенча программа материалын үзләштерүләрен ачыклау.

Безнең хәзерге җәмгыять фән һәм техника прогрессы белән бәйләнгән. Мәгълүмати коммуникатив технологияләр кеше тормышының бөтен тармагына да үтеп кергән.

Туганда ук инде баланы өйдә, балалар бакчасында, шифаханәдә электрон дөнья әйләндереп алган.

Яңа мәгълүматлар, рекламалар, электрон уенчыклар - болар барысы да мәктәпкәчә яшьтәге балаларга аеруча тәэсир итә. 5-6 яшьлек бала компьютерда шөгыльләнгәндә үзенә иң кызыксындырган мәгълүматны гына ала, үзен комфортлы хис итә. Шуңа аның уенының да характеры үзгәрә. Безгә дә элеккеге традицион методларны яңа алымнарга алыштыру бурычы куела. Хәзерге үсеш процессында бер урында таптанып тору мөмкин түгел. Шуңа күрә, заман яңа мәгълүмати технологияләр куллануны таләп итә.

Укыту методик кулланма (УМК) белән эш процессында, ничек итеп баланы кызыксындырырга, яңарак технологияләр кулланырга дигән актуаль проблема туды. Балаларны татар теленә өйрәтү өчен, укыту методик кулланманың үзендә анимацион сюжетлар, мультфильмнар, аудио – видео язмалар җитәрлек дәрәҗәдә бар. Балаларга татар теле өйрәткәндә алар бик уңышлы кулланыла. Тик балаларның программа материалын үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү процессы элеккегечә, уенчыклар күрсәтеп, сорау – җавап формысында кала бирә. Хәзерге замана балаларында бу кызыксыну уятмый диярлек. Шуңа күрә, яңача технологияләр эзләргә булдык һәм УМК ның үзеннән чыгып, татар теле өйрәтү буенча программа материалын үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү өчен мультимедия дидактик уеннар эшкәртмәсе ясадык.

Тәгъдим ителгән уеннар һәм уен ситуацияләре уртанчылар төркеме, зурлар төркеме, һәм мәктәпкә хәзелек төркемнәрендә татар теле өйрәнүче балаларның укыту методик кулланма буенча программа материалын үзләштерүләрен ачыклау өчен ясалды. Тикшерү процессы ахырынача дидактик уеннар формасында корылган. Бала уйный, ә тәрбияче уеннар барышында үз алдына куйган максатка ирешә: программа материалының үзләштерелүен билгели, баллар куеп бара. Уеннар яшь үзенчәлекләренә карап, программа таләпләренә туры китереп төзелде, һәр төркем өчен аерым бер сюжетка корылды. 4-5 яшьлек балалар өчен УМК белән эш барышында кулланыла торган, балаларга бик таныш булган персонажлар Мияу белән Акбай белән уйнауга корылды. 5 - 6 яшьлек балалар Алсу исемле татар кызы белән бәйле сюжетлар аша төрле ситуацияләрдә булалар. 6-7 яшьлек балалар Оля һәм Коля белән татарча әңгәмә кору аша төрле дидактик уеннар уйныйлар.

Без тәгъдим иткән уеннар тәрбиячене диагностика үткәрү өчен әзерлисе булган күп эштән азат итәләр (уенчыклар, рәсемнәр әзерләү, сюжетлы уеннар оештыру һ. б.). Бу уеннар белән кулланганда бары тик үзеңнең уеннар белән дөрес куллана белүең һәм баллар куеп барыр өчен дәфтәр булуы гына кирәк.

Диагностика елыны 3 тапкыр уздырыла. Ел башында һәм ел ахырында уеннар бөтенесе дә уйнатыла, ә ел уртасында үткән темаларга кагылышлы булганнары гына уйнатыла. УМК белән эшләү барышында балалар аудио язмаларга, тавыш яздырылган анимацион сюжетларга күнектеләр. Аларда бу кызыксынуларын арттыра, өйрәтү процессын җиңеләйтә. Шуңа күрә, уеннарны тавышлы итеп эшләдек.

**Мультимедиа дидактик уеннарны уйнатканда тәрбиячегә киңәшләр:**

1. Уеннарны балаларга күрсәткәнче үзеңә аңлап, күрсәтергә өйрәнергә.
2. Һәр уенның бала өчен яздырылган тавышлы аңлатмасы бар (сары төстәге громмофон рәсеме). Әгәр ул бер генә булмаса, аларга чиратлап басу өчен саннар куелган. Тавышны тыңлатканнан соң, компьютер кнопкасы аша хәрәкәтләндерү каралган. Бу барлык уеннарда да шулай эшләнгән.
3. Коррекция яисә индивидуаль эш өчен кулланганда, уеннарны рәттән уйнатмыйча, кирәкле теманы гына сайлап уйнатырга кирәк.

**Уеннарны үткәрү алымнары :**

1.Тәрбияче үзе уеннарны өйрәнә.
2. Балаларны проблемалар белән таныштыра, нинди максат куелганын аңлата, юнәлеш бирә.
3. Проблема һәм максат балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килергә тиеш. Тәрбиячегә максатны кыска, аңлаешлы итеп аңлатырга кирәк. Бала үзенең ни эшләргә тиеш икәнен аңласын.
4. Балалар кайбер урында ялгышса, тәрбияче балага әйтеп җибәрә.
5. Уен тәмамлангач пауза ясарга, авыр халәттән чыгарга, нәтиҗә ясарга.
6. Анализ вакытында баланың игътибарын эмонациональ халәтенә карап билгелиләр (нәрсә ошады, нәрсә авыр булды, ситуация ничек үзгәрде, нәтиҗә нинди?) Иң мөһиме бала уеннан зур канәгатьләнү алырга тиеш.

**Мәгълүмати коммуникатив технологияләрне куллану санитар гигиена таләпләренә туры килергә тиеш.**

5 яшьлек балалар компьютерда - 10 минут.
6-7 яшьтә - 15 минут эшләргә.
Балалар белән экран арасы 2-3 м. дан алып 5-5,5 м. дан артмасын.
5-7 яшьлек балалар белән уеннар көнгә 1 тапкыр, атнага 2-3 тапкыр үткәрелә. Эшчәнлек ахырында күзгә гимнастика ясарга кирәк.

| **Яшь үзенчәлекләре буенча уеннар бүленеше** | | |
|---|---|---|
| **Уртанчылар төркеме** | **Зурлар төркеме** | **Мәктәпкә әзерлек төркеме** |
| **I.Сүз байлыгы:** | **I. Сүз байлыгы** | **I. Сүз байлыгы** |
| 1. Д.Уен “Бу нәрсә?”<br>2. Д.Уен “Бу кем?”<br>3. Д.Уен “Кем юк?”<br>4. Д.Уен “Кәрзиндә нәрсә бар, нәрсә юк?” | 1. Д.Уен “Кем бар?”<br>2. Д.Уен “Өйдә кем яши?”<br>3. Д.Уен “Нәрсә бар нәрсә юк”<br>4. Д.Уен “Тәрҗемәче” | 1.Д. Уен “Син кем?”<br>2.Д. Уен “Әбидә кунакта”<br>3.Д. Уен “Бу нинди җәнлек?”<br>4.Д. Уен “Нәрсә |

| | | |
|---|---|---|
| 5. Д.Уен “Серле янчык”<br>6. Д.Уен “Әйе, юк” | | артык?”(киемнәр, савыт – саба, мебель)<br>5.Д. Уен “Әнигә булышабыз” |
| **II. Ягымлы сүзләр куллану** | **II. Ягымлы сүзләр куллану** | **II. Ягымлы сүзләр куллану** |
| 1.Уен ситуациясе «Рәхмәт”<br>2. Уен ситуацияләре “Исәнме”, “Сау бул”, ”Рәхмәт” | 1. Уен ситуациясе “Исәнме”, “Исәнмесез”,“Сау бул”, “Сау булыгыз”, “Рәхмәт” | 1.“Кыш бабай бүләкләре ”<br>2.“Танышу” |
| **III. Санау күнекмәләрен булдыру<br>(1-5)** | **III. Санау күнекмәләрен булдыру** | **III. Санау күнекмәләрен булдыру** |
| | **IV. Боерык бирә белү** | **IV. Боерык бирә белү** |
| | 1.Д.Уен “Командир” | 1.Д. Уен” Кунаклар сыйлау”<br>2. Д. Уен “Без циркта ” |
| **IV. Тирә - юньдәге предметларның сыйфат, билгеләрен белдерә торган сүзләр куллану.** | **V. Уен ситуациясендә үзлектән сорау бирә белү** | **V. Уен ситуациясендә үзлектән сорау бирә белү** |
| 1. Д.Уен “Уенчык нинди?”<br>2.Д.Уен “Чиста пычрак” | 1. Д. Уен “Савыт – саба кибетендә ” | 1. Д. Уен “Рәсем турында сөйлә”<br>2. Д. Уен “Чыршыны бизә”.<br>3.“Нинди шар юк?” |
| **V. Боерык бирә белү<br>VI. Аралаша белү** | **VI. Аралаша белү** | **VI. Аралаша белү** |
| 1.Уен ситуациясе “Әйдәгез, танышабыз”<br>2. Уен ситуациясе “Кунаклар”<br>3.Уен ситуациясе “Уенчыкларны ю!” | 1. Д.Уен “Яңа өйгә күчү”<br>2. Д.Уен “Яшелчәләр кибете”<br>2. Д.Уен “Безнең кунаклар”<br>3.Д.Уен “Рәсем турында сөйлә” | 1.Д. Уен “Яшелчәләр турында сөйлә”<br>2.Д. Уен “Портфельдә нәрсә бар? |

# Уртанчылар төркеме балалары өчен “Минем өем” проекты буенча диагностика үткәрү мультимедиа уеннары

**I.Сүз байлыгы**

**“Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.**

Сүз байлыгы балаларның проект буенча үзләштергән лексик минимумын чагылдыра. Түбәндәге дидактик уеннар ярдәмендә баланың сүз байлыгы нинди дәрәҗәдә икәнлегенә гомуми нәтиҗә куела:

Югары балл (2,7-3) - сүз байлыгы җитәрлек, уенчык, әйберләрне үзлектән, аңлап дөрес итеп исемнәрен әйтә.
Уртача балл (2-2,6) - сүз байлыгы бар, кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.
Уртачадан түбән балл (1-2) - аңлый, русча җавап бирә.

***1. Дидактик уен:"Бу нәрсә?"***
Лексика: куян, эт, песи,алма, машина, сөт,туп, аю, курчак.
- Бу нәрсә?
- Бу туп...

***2. Дидактик уен. "Бу кем?"***
Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай
- Бу кем?
- Бу әни...

***3. Дидактик уен. "Кем юк?"***
Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай
- Кем юк?
- Әни юк. Әни кил монда...

**4. *Дидактик уен "Кәрзиндә нәрсә бар?", "Нәрсә юк?"***
а) (Лексика: ипи, алма, сөт, чәй)
- Бу нәрсә?
- Алма..
б) (Лексика: ипи, алма, сөт, чәй)
Дидактик уен "Нәрсә юк?"
-Нәрсә юк?"
-Ипи юк...

***5. Дидактик уен "Серле янчык"***
(Лексика: куян, аю, туп, машина,курчак, эт, песи)
Уен эчтәлеге: балалар табышмак чишәләр, аннан соң исемен татарча әйтәләр. янчыктан уенчык чыга.

***6. Дидактик уен "Әйе-юк"***
Сүзнең дөрес үзләштерелүен тикшерү (механик рәвештә генә отып калу булмасын
өчен ) төрле вариантта сораулар бирелә:
- Бу нәрсә?
- Аю...;
- Бу аю?
- Әйе,аю;
- Бу куян?

- Юк, песи...

**II. Ягымлы сүзләр куллану**
“Исәнме". "Сау бул". "Рәхмәт".
Югары балл (2,7-3) - бала ситуацияләрдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.
Уртача балл (2-2,6) – тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.
Уртачадан түбән (1-2) - аңлый, сорауга җавапны русча әйтә.
**1."Рәхмәт"**
-Алсу, мә курчак.
-Рәхмәт...
**2*."Исәнме", "Сау бул", "Рәхмәт"***
- Исәнме Акбай
- Исәнме, Мияу.
- Мә чәй эч.
- Рәхмәт
- Мә алма , аша.
- Рәхмәт
- Сау бул,Акбай.
- Сау бул, Мияу.

**III. Санау күнекмәләрен билгеләү (1-5 кадәр).**
Югары дәрәҗә (2,7-3) - дерес саный, санны исем белән әйтә. ("Биш туп"...)
Уртача дәрәҗә (2-2,6) -санаганда ялгыша.
Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2) - русча саный.
- Ничә туп?
- 3 туп...

**IV. Бәйләнешле сөйләм**

**Тирә - юньдәге предметларның сыйфат билгеләрен, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану, аларны исемнәр белән бергә әйтү.*“Нинди?"* соравына аңлап җавап бирү.** (Әйберләрне билгесен ачыклау өчен бирелә торган сорауга аңлап җавап бирү.
Югары дәрәҗә (2,7-3) - әйберләрнең сыйфат билгеләрен, күләмен дөрес әйтә.
Уртача дәрәҗә (2-2,6) - 1-2 билгесен әйтә.
Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2) - әйберләрнең билгеләрен, күләмен рус телендә әйтә.
***1. Дидактик уен "Уенчык нинди?" (зур, кечкенә).***
- Нинди курчак?
- Зур (кечкенә) курчак...

**V. Аралаша белү: сорауларга аңлап, өйрәнгән лексиканы кулланып җавап бирү, ягымлы сүзләр куллану, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау, боерыкларны бирү күздә тотыла.**
Югары дәрәҗә (2,7-3) - аралаша, сөйләм күнекмәләрен актив куллана.

Уртача дәрәҗә (2-2,6) - тәрбияче ярдәмендә аралаша.
Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2) - аңлый, русча җавап бирә.

**1.** ***Уен ситуациясе "Әйдәгез танышабыз".***
"Син кем?" соравына аңлап җавап бирүе билгеләнә.
К нам пришла Алсу, она хочет с вами познакомиться:
-Исәнмесез. Мин Алсу. Син кем? (Мин Оля (Коля).
-Мин Алсу, мин кыз. Син кем?
-Мин Оля, мин кыз...

**2.** ***Уен ситуациясе "Кунаклар".***
К нам пришли гости. Как они здороваются?
- Исәнмесез.
- Позови бабушку (дедушку)сесть за стол.
- Әби (бабай), кил монда, утыр
- Предложи бабушке (дедушке) пить чай...
- Мә, чәй, эч.
Скажи: " До свидания!"
- Сау бул, әби! (бабай)...

***3. Дидактик уен "Уенчыкны ю!"***
-Курчак ю!
-Туп ю!..

# Зурлар төркеме балалары өчен “Уйный, уйный үсәбез” проекты буенча диагностика үткәрү мультимедиа уеннары

**I. ”Сүз байлыгы”.**
**“Уйный, уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.**
Югары балл (2,7-3) – сүз байлыгы җитәрлек, аңлап дөрес күрсәтә, исемен әйтә.
Уртача балл (2-2,6)- сүз байлыгы бар, кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә

җавап бирә.
Уртачадан түбән балл (1 -2) – аңлый, русча җавап бирә.

1. ***Дидактик уен “Кем бар?,***
(лексика: әти, әни, бабай, әби, кыз, малай, песи, эт һәм “бар” “юк” ).
- Кем бар?
-Бабай бар.

***2. Дидактик уен. “Өйдә кем яши?”(***лексика: әти, әни, бабай, әби, кыз, малай, песи, эт).
Уен эчтәлеге: Өй рәсеме, өй тирәсендә гаилә әгъзәләре, песи һәм эт.
- Бу кем? (әни....), Бу нәрсә?- (песи, эт ).

***3. Дидактик уен “Кәрзиндә нәрсә бар?”***
(кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, помидор)
Уен эчтәлеге: Акбай кәрзин белән яшелчәләр алып килгән.
- Нәрсә бар?
- Суган бар...
***Нәрсә юк?”.,***
Уен эчтәлеге: (кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, помидор)
Уен эчтәлеге: Акбай кәрзин белән яшелчәләр алып килгән.
- Нәрсә юк?
- Суган юк...

***4. Дидактик уен “Терҗемәче”***
(лексика: кашык, тәлинкә, чынаяк. яшел
тәлинкә, кызыл чынаяк, зәңгәр кашык, зур... кечкенә...)
Уен эчтәлеге:
Тәрбияче сүзләрне рус телендә әйтә, ә бала әйткән сүзнең рәсемен курсәтеп татарча әйтә.
- Желтая тарелка
- Сары тәлинкә...

**II. Ягымлы сүзләр куллану**
Югары балл (2,7-3) - бала ситуацияләрдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.
Уртача балл (2-2,6) – тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.
Уртачадан түбән (1-2) - аңлый, сорауга җавапны русча әйтә

***1. Уен ситуациясе “Исәнме”, “Сау бул”, “Рәхмәт”, “Хәлләр ничек?”***
Азат пришел в гости к Алсу. Какие они вежливые слова говорят друг – другу при встрече, при угощении друг – друга и при прощании.
- Исәнме, Алсу.

- Исәнме, Азат
- Хәлләр ничек?
- Әйбәт, рәхмәт...

***III. Санау күнекмәләрен билгеләү (10 кадәр).***

Югары дәрәҗә (2,7-3) - дөрес саный, санны исем белән әйтә. (“сигез туп"...)
Уртача дәрәҗә (2-2,6) -санаганда ялгыша.
Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2) - русча саный.
- Ничә туп?
- 8 туп...

**IV. Боерыкны аңлап үтәү һәм бирү**

Югары дәрәҗә (2,7-3 )- бала боерыкны аңлап дөрес үти.
Уртача дәрәҗә (2-2.6) – ялгыша
Уртачадан түбән (1-2) - татарча аңламый, боерыкларны үтәми.

**1. *Дидактик уен: “Командир”***

(лексика: утыр, кил монда, сикер, ю, уйна, ки, сал, аша, эч.)
-Ребята, давайте поиграем в игру “Командир”. Сначала я буду командовать, а потом вы.
- Аша!
- Сикер!..

**V. Уен ситуациясендә үзлектән сорау бирә белү.**

Тирә-юньдәге преметларның сыйфат билгеләрен, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану, аларны исемнәр белән бергә әйтү. “Нинди?” соравына аңлап җавап бирү. (Әйберләрне билгесен ачыклау өчен бирелә торган сорауга аңлап җавап бирү).
Югары дәрәҗә (2,7-3 )- бала үзлектән аңлап сорау бирә белә.
Уртача дәрәҗә (2-2.6) – ялгыша
Уртачадан түбән (1-2) – рус телендә бирә.

***1. Дидактик уен “Савыт – саба кибетендә”***

(савыт - саба исемен һәм билгесен әйтү- тәлинкә кызыл, матур, зур. Чынаяк кечкенә, сары.
- Миңа тәлинкә кирәк.
- Нинди?
- Кызыл, зур, матур.
- Ничә?...

**VI. Аралаша белү.**

Сорауларга аңлап, өйрәнгән лексиканы кулланып җавап бирү, ягымлы сүзләр куллану, чакыру, сайлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау, боерыкны бирү күздә тотыла, сораулар бирү, мөрәҗәгать итү.
Югары дәрәҗә (2,7-3) - аралаша, сөйләм күнекмәләрен актив куллана.
Уртача дәрәҗә (2-2,6) - тәрбияче ярдәмендә аралаша.
Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2) - аңлый, русча җавап бирә.

***1. <u>Дидактик уен “Яңа өйгә күчү”</u>***
(лексика: урындык, өстәл, карават,тәлинкә, чынаяк, кашык, )
- Бу нәрсә?
- Карават
- Нинди?
- Сары карават...

2. ***<u>Уен ситуациясе "Безнең кунаклар".</u>***
К нам пришли гости. Как они здороваются?
- Исәнмесез.
- Позови бабушку (дедушку) сесть за стол.
- Әби (бабай), кил монда, утыр
- Предложи бабушке (дедушке) пить чай...
- Мә, чәй, эч...

***<u>3 . Дидактик уен “Яшелчәләр кибете”.</u>***
(Лексика: кәбестә, кишер, кыяр, суган, бәрәңге)
Сатып алучылар ролендә балалар.
- Сиңа нәрсә кирәк?
- Кәбестә кирәк
- Нинди кәбестә?
- Яшел, зур, тәмле кәбестә
- Ничә кәбестә?
- Алты кәбестә...

## Мәктәпкә хәзерлек төркеме балалары өчен “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча диагностика үткәрү мультимедиа уеннары

**<u>I.”Сүз байлыгы”.</u>**
Сүз байлыгы балаларның проект буенча үзләштерелгән лексик минимумын чагылдыра. Түбәндәге сүзле, дидактик уеннар ярдәмендә баланың сүз байлыгы нинди дәрәҗәдә икәнлегенә нәтиҗә куела.

Югары балл (2,7-3)- сүз байлыгы җитәрлек, уенчык, әйберләрне үзлектән, аңлап дөрес күрсәтә, исемнәрен әйтә.
Утача балл(2-2,6)- сүз байлыгы бар, кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.
Уртачадан түбән балл (1-2)-аңлый, русча җавап бирә.

***1. Дидактик уен. ”Син кем?”***
(лексика: син, мин, кыз, малай, кем?)
Тәрбияченең кулында туп. Экранда туп юкка чыккач,тәрбияче ярдәмендә балалар уенны дәвам итәләр.
- Мин Оля, мин кыз (передает мяч )
- Мин Коля, мин малай (передает мяч)...

2. ***Дидактик уен. “Әбидә кунакта”***
(лексика: үрдәк, тавык, әтәч,песи, эт)
Оля и Коля пришли к бабушке в гости и увидели домашних птиц и животных.
- Бу нәрсә?
- Бу үрдәк...

***3. Дидактик уен ”Бу нинди җәнлек?”*** (лексика: аю, бүре, куян, төлке, керпе, тычкан). Урман рәсеме. Урманда аю, бүре, куян, төлке, керпе фигуралары килеп чыга.
- Бу нәрсә?
- Бу бүре...
һәм шул рәвештә балалар үзләре бер-берсенә сорау бирәләр.

***4.Дидактик уен “ Нәрсә артык?”*** (лексика: киемнәр, савыт – саба, мебель, мәктәп өчен кирәк – яраклар). 4 рәсем күрсәтелә, балалар артык әйберне әйтәләр.
- Нәрсә артык?..

***5. Дидактик уен “Әнигә булышам”***
(лексика: кыяр, кишер, алма, помидор, суган,  бәрәңге, кәбестә, груша, виноград).
Уен эчтәлеге : Кәрзиндә яшелчәләр һәм җимешләр . Өстәлдә салат өчен саавыт һәм компот өчен кәстрүль.
- Ребята,, помогите маме и Оле выбрать фрукты для компота и овощи для салата”.( Балалар яшелчәләрне сайлап исемнәрен әйтәләр.Шул тәртиптә җимешләрнең исемнәрен дә әйтәләр).
**II. Ягымлы сүзләр әйтү.**
Югары балл(2,7-3)- бала ягымлы сүзләрне урынлы куллана.
Уртача балл (2-2,6) – тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.
Уртачадан түбән (1-2)- аңлый, сорауга җавапны русча әйтә.

***<u>1. Дидактик уен “Кыш бабай бүләкләре”</u>***
(лексика:китап, дәфтәр, альбом, линейка,исәнмесез, рәхмәт.)
Пришет Дедушка Мороз и подарки вам принес.Как вы умеете встречать Деда Мороза и благодарить за подарки.
- Исәнме, Кыш бабай.
- Бу китап, рәхмәт...

***<u>1. Дидактик уен “Дустыңны сыйла!”</u>***
(лексика:исәнме, сау бул,хәлләр ничек, хәерле көн, рәхмәт, сау бул)
–Коля пришел в гости к Оле . Какие вежливые слова они говорят друг – другу при встрече, при угощении, во время прощания.
- Исәнме, Оля
- Исәнме, Коля
- Хәлләр ничек
- Әйбәт, рәхмәт...

**III. Санау күнекмәләрен билгеләү (10 кадәр).**
<u>Югары дәрәҗә (2,7-3)</u> - дөрес саный, санны исем белән әйтә. (“ун тавык"...)
<u>Уртача дәрәҗә (2-2,6)</u> -санаганда ялгыша.
<u>Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2)</u> - русча саный.
- Ничә тавык?
- Ун тавык...

**IV.Боерык бирә белү**
Югары дәрәҗә (2,7-3 )- бала боерыкны аңлап дөрес үти.
Уртача дәрәҗә (2-2.6) – ялгыша
Уртачадан түбән (1-2) - татарча аңламый, боерыкларны үтәми.

***<u>1. Дидактик уен”Кунакларны сыйла!”</u>***
Ребята, вам пришли гости,как вы их будете угощать?
-Бабай, мә өчпочмак, аша !
-Әби, мә чәк – чәк, аша...

***<u>2. Дидактик уен “Без цирктa”</u>***
- Мы в цирке. Скажите, мальчик какие команды дает собаке. А потом командуйте сами.
- Эт, сикер!
-Эт, җырла!..

**V. Уен ситуациясендә үзлектән сорау бирү.**
Югары дәрәҗә (2,7-3 )- Үзлектән аңлап сорау куя белә.
Уртача дәрәҗә (2-2.6) – ялгыша
Уртачадан түбән (1-2) – рус телендә сорый

***<u>1.Дидактик уен “Чыршыны бизә”</u>***

- Мыукрасим ёлку разноцветными шарами. Спросите друг у друга какие шары повесили.
-Бу нинди шар?
Ак шар...

***2.Дидактик уен “Нинди шар юк?”***
(лексика: ак, кара, сары, яшел, зәңгәр, кызыл, нинди, юк)
- У Оли и Коли разноцветные шары. Спросите друг у друга какого шара нет.
- Нинди шар юк?
- Кара шар юк...

***3. Дидактик уен “Кем нишли?***
(лексика: укый, йоклый, сикерә, җырлый, бии, утыра, йөгерә)
- Расскажите кто, что делает?
- Кыз нишли?
- Кыз диванда йоклый...

**VI. Аралаша белү.**
Югары балл (2,7-3)- сүз байлыгы җитәрлек, үзлектән, аңлап җөмлә төзеп сөйли.
Утача балл(2-2,6)- сүз байлыгы бар, кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.
Уртачадан түбән балл (1-2)-аңлый, русча җавап бирә.


***1.Дидактик уен. “Рәсем турында сөйлә”***
Сюжетлы рәсемнәр эчтәлеге:
- Бу куян. Куян кишер ашый.
- Бу песи. Песи сөт эчә.
- Бу аю. Аю йоклый.
- Бу эт. Эт йөгерә.
- Бу кыз. Кыз кул юа.
- Бу бабай. Бабай йоклый.
- Бу төлке. Төлке утыра.
- Бу малай. Малай рәсем ясый.
- Бу үрдәк. Үрдәк җырлый.
- Бу тычкан. Тычкан бии.
- Бу бүре. Бүре китап укый.
- Бу әни. Әни бит юа.
- Бу әти. Әти алма ашый.
- Бу кыз. Кыз чана шуа.
- Бу куян. Куян сикерә.

***2.Уен ситуациясе “Портфельне тутыр”.***
(лексика: ручка, китап, пенал, дневник, альбом)

- Портфели пустые. Чтобы наполнить их, надо попросить вежливо. (Карандаш бир әле).
- Карандаш (ручка, китап, пенал, дневник, альбом) бир әле.-
- Мә, карандаш (ручка, китап, пенал, дневник, альбом).
- Рәхмәт...

***3.Үстерешле диалог "Телефоннан сөйләшәбез".***
- Алло.
- Син кем?
- Мин Оля.
- Исәнме, Оля.
- Хәерле көн, Коля. Хәлләр ничек?
- Әйбәт. Рәхмәт. Саша, хәлләр ничек?
- Син нишлисең?
- Мин китап укыйм..
- Син нишлисең?
- Мин рәсем ясыйм.
- Сау бул, Оля.
- Сау бул, Коля.

## Зарядка для глаз при работе с компьютером



1. Расслабление. Плотно закройте глаза и постарайтесь расслабиться.
2. Круговые движения. Сделайте круговые движения открытыми глазами: сначала по часовой стрелке, затем против часовой.
3. Движения по прямым линиям. Интенсивно подвигайте глазами по горизонтали: направо и налево, и вертикали: вверх и вниз.
4. Моргание. Интенсивно сжимайте и разжимайте глаза.
5. Диагонали. Направьте взгляд в левый нижний угол, то есть посмотрите как бы на левое плечо и сосредоточьте взгляд на этой точке. После трех морганий повторите в правую сторону.

## Веселая зарядка для глаз

**Понедельник**

Всю неделю по — порядку,
Глазки делают зарядку.
В понедельник, как проснутся,
Глазки солнцу улыбнутся,
Вниз посмотрят на траву
И обратно в высоту.

# Кулланылган әдәбият:

1. Зарипова З.М.  Татарча сөйләшәбез – Казань: «Хәтер», 2012.